| | | |
|---|---|---|
| “Каралды”<br>Методик берләшмә җитәкчесе:<br>___________ М.С. Фәттахова.<br>Беркетмә № 1<br>“ 26 ” август 2021 ел. | “Килешенде”<br>Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары: __________Р.Г. Тухфатуллина.<br><br>“ 28 ” август 2021 ел. | “Раслыйм”<br>Директор:<br>__________ Р.Г.Җамалиев<br>Приказ № 75<br>“ 28 ” август 2021 ел. |

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авылы җирлеге “Утыз Имән” төп гомуми белем бирү мәктәбе
гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе.

2021 - 2022 нче уку елы өчен
9 сыйныфка туган (татар) әдәбиятыннан
эш программасы

Укытучы: Миневәлиева Минзирә Кадыйр кызы.

**Аңлатма язуы**

**Программа түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп язылды**

- Россия Федерациясендә мәгариф турында" Россия Федерациясенең федераль Законы (29.12.2012 №273-ФЗ)

- "Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законы (гамәлдәге редакциядә)

- Гомуми төп белем бирү дәүләт стандартының Федераль компоненты (ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 05.03.2004 нче елгы №1089 карары нигезендә расланган).

-"2014-21 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү" буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы.

- Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары (5-11 нче сыйныфлар). – Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2020.

- Муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Утыз Имән төп гомумбелем бирү мәктәбе"нең укыту планы. (28.08.2021 нче ел датасы белән чыгарылган 75 нче № лы боерык)

Укыту түбәндәге дәреслеккә нигезләнеп алып барыла:

1. Миңнегулов Х.Й., Садретдинов Ш.Ә. Әдәбият (Борынгы һәм Урта гасыр, XIX йөз татар әдәбияты): Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең һәм гимназияләренең 9 нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен дәреслек . – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2017

2. Миңнегулов Х.Й., Садретдинов Ш.Ә. Әдәбияттан хрестоматия. Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 9 нчы с-фы өчен. – Казан: Мәгариф, 2015

Программа 2021 – 2022 нче уку елына атнага 2 сәгать исәбеннән (ел буена барысы 68 сәгать) төзелә. 9 нчы сыйныф өчен программада татар әдәбиятына 68 дәрес каралган, эш программасында да уку елы дәвамында 68 дәрес үткәрү планлаштырыла. һәр тема программада каралган сәгать санынча өйрәнелә. Аерма бары тик "Кыйссаи Йосыф" әсәрен өйрәнү дәресләренә генә карый: ул бер дәрескә арттырылды. Аның өчен йомгаклау һәм имтиханга әзерләнү дәресләреннән бер сәгать алынды.

Эш программасының төп идеясе – татар әдәбиятыннан белем бирү процессын планлаштыру, оештыру һәм идарә итү өчен шартлар булдыру. Программа төп өч функцияне үти:

- мәгълүмати-методик функция уку-укыту процессының барлык катнашучыларына 9 нчы сыйныф укучыларының белем, тәрбия эчтәлеге һәм максаты турында күзаллау булдыру;
- оештыру-планлаштыру функциясе укыту материалының төзелеше, аның сыйфаты һәм күләмен билгели;
- контроль функциясе белем бирүнең һәр этабында укучыларның белем алу дәрәҗәсенә, аралашу күнекмәләренә нәтиҗә ясау мөмкинлеге бирә.

Татар әдәбиятын укыту укыту процессында мөһим урынны алып тора. Әдәбият халыкның гасырлар буена бөртекләп килгән акыл һәм рухи байлыгын тәшкил итә. Халык күңелендә лаеклы урын алган мөһим эчтәлекле әсәрләрне өйрәнү милләтнең күпгасырлык рухи хәзинәсен, тарихын, гореф-гадәтләрен өйрәнү, үзләштерү өчен кирәк. Бу, үз чиратында, яшь буында үз милләте, Ватаны белән горурлану хисләре тәрбияли.

Татар әдәбияты "Әдәбият" белем бирү өлкәсенә карый, гуманитар фәннәр циклына керә.

Татар әдәбияты укытуның өченче баскычында түбәндәге төп **максатлар** билгеләнә:

1. Татар әдәбиятының тарихи барышы турында гомуми караш булдыру.
2. Татар әдәбиятының барышын, аның аерым чорлардагы торышын, чор әдәбиятының йөзен билгеләүче язучылар иҗатын анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.
3. Әдәби-теоретик белемнәр нигезендә әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының, гомумән, татар әдәбиятының үзенчәлекләрен табарга күнектерү.
4. Текст һәм башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү.
5. Иҗади фикерләүдәге уртак һәм милли үзенчәлекләрне танырга өйрәтү.

9 нчы сыйныфта татар әдәбияты курсы сүз сәнгатенең тарихи үсешен системалы күзаллау булдыру һәм шуның аша классик һәм бүгенге әдәбиятның үзара бәйләнешен тулырак аңлауны күз алдында тота.

Укучыларга түбәндәге мәгълүматлар җиткерелә:

- Әдәби әсәрләрнең тарихи-конкрет һәм гомумкешелек кыймммәтләрен ачу өчен кирәкле;
- Әдәбияттагы "үтәли" һәм "мәңгелек" проблемаларны ачыклый торган;
- Сүз сәнгатенең аерым күренешләре белән мөстәкыйль танышу һәм аларның эстетик кыймммәтен бәяләү өчен кирәкле;
- Татар әдәбиятының рус һәм дөнья әдәбияты мәйданындагы урынын һәм ролен бәяләргә ярдәм итүче.

**Бурычлар**

Өйрәнелгән әдәби әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзалларга ярдәм итү.

1. Әдәби әсәрнең эстетик кыймммәтен, төрен һәм жанрын билгеләргә өйрәтү.
2. Әдәби әсәрне анализлау күнекмәләре булдыру.
3. Шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрләрдән өзекләрне ятлату.
4. Укучының мөстәкыйль фикерләвен, гомумиләштереп нәтиҗәләр ясау сәләтен үстерү.
5. Бәхәсләрдә катнашу, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларыңны раслау һәм дәлилләү күнекмәләре булдыру.
6. Рефератлар, докладлар әзерләргә өйрәтү.
7. Әдәби әсәрләр һәм ирекле темалар буенча сочинение язу күнекмәләрен үстерү.
8. Әдәбият теориясе, әдәбият тарихы, сәнгатьнең башка төрләре бергәлегендә укучыда әдәбиятны мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият-сәнгать белән даими кызыксыну тәрбияләү.
9. Матур әдәбиятта халык тарихы, милләт язмышы гәүдәләнешенә укучыларның игътибарын туплау.
10. Әдәби әсәрнең эстетик кыймммәтен, поэтикасын аңларлык эстетик зәвык булдыру.
11. Укучыларда кешелеклелек, горурлык, үз кадереңне белү хисләре тәрбияләү.

Укыту процессының төп характеристикасы:

1.Эш формалары: сыйныф белән, группалап, индивидуаль, парлап, фронталь, дифференциаль.

2.Укыту методлары: сөйләү, күрсәтмәлелек, практик, эзләнү, проблемалы, мөстәкыйль эш, стимуллаштыру, тикшерү.

Татар әдәбиятын өйрәнү түбәндәге фәннәр белән тыгыз бәйләнештә:

1) сәнгатьнең башка төрләре ярдәмендә укучыда әдәбиятны мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият-сәнгать белән даими кызыксыну тәрбияләү, әдәбиятның сәнгать төре буларак, үзенчәлекләрен тулырак ачыклау;
2) әдәбиятны татар теле белән бәйләп, чор әдәбияты стиле, иҗат юнәлешләре стиле, язучы стиле кебек төшенчәләрне җиткерү;

3) татар әдәбиятын рус әдәбияты белен бәйләп, әдәби әсәрне, язучы иҗатын, чор әдәбиятын анализларга күнектерү; татар әдәбиятының рус һәм дөнья әдәбиятлары мәйданындагы урынын, дәрәҗәсен билгеләү;

4) әдәбиятны тарих һәм җәмгыять белеме предметлары белән бәйләп, әдәбиятны чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзаллау формалаштыру.

**Татар әдәбиятыннан тематик план**

Атнага 2сәгать исәбеннән (35 атна, 68 сәгать)

*Әсәрләрне өйрәнү – 50 сәгать*

*Сөйләм үстерү – 8 сәгать*

*Дәрестән тыш уку – 8 сәгать*

*Кабатлау һәм имтиханга әзерләнү – 3 сәгать*

***Программа:*** Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары. 5-11 нче сыйныфлар/ Ф.Хатипов, А.Әхмәдуллин. К., “Мәгариф”, 2018

***Дәреслек:*** Ә.М.Закирҗанов, Г.М.Фәхретдинова. Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. Ике кисәктә- Казан - Татарстан китап нәшрияты, 2016.

9 нчы сыйныф өчен дәреслек.

| № | *Тема* | *Сәгать саны* | Дата | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План буенча | Факт буенча |
| 1 | Сәнгать төре буларак әдәбият. Татар әдәбиятының чорларга бүленеше.<br>Әдәбиятның барлыкка килүе һәм үсеше | 1 | | |
| 2 | Гомумтөрки әдәбият. Күлтәгин истәлегенә куелган таштагы кече язмадан үрнәкләр. | 1 | | |
| 3-5 | Уйгур язулы истәлекләр. Гарәп язулы истәлекләр: М.Кашгарый “Диване лөгатет-төрк”, Й.Баласагунлы “Котадгу белек”. Әдәбият теориясе. Матур әдәбиятның иҗтимагый вазифасы. | 3 | | |
| 6 | Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани иҗатлары турында кыскача мәгълүмат бирү. | 1 | | |
| 7-8 | Ислам мәдәнияте. Коръән. Ислам дине һәм төрки-татар мәдәнияте.<br>Суфичылыкның | 2 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | әдәбиятта чагылышы. | | | |
| 9 | Урта гасырлар әдәбияты. Болгар-Хәзәр чоры әдәбияты. Шәхес һәм шагыйрь буларак Кол Гали турында белешмә. “Кыйссаи Йосыф” поэмасының язылу һәм яшәү тарихы. | 1 | | |
| 10 | Алтын Урда чоры әдәбиятына күзәтү.<br>Котб “Хөсрәү вә Ширин | 1 | | |
| 11 | Казан ханлыгы әдәбиятына кереш. Мөхәммәдьярның тәрҗемәи хәле. “Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” поэмалары.<br>. | 2 | | |
| 13 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. “Мөхәммәдьяр – гуманист шагыйрь” дигән темага әңгәмә. Татар поэзиясен үстерүгә Мөхәммәдьяр керткән өлеш.<br>Казан ханлыгы чоры әдәбиятына йомгак. | 1 | | |
| 14-15 | Торгынлык чоры әдәбияты ( 16 гасыр уртасы-19 гасыр | 2 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | уртасы).<br>Мәүла Колыйның тәрҗемәи хәле. “Хикмәтләр”ен уку һәм анализлау. | | | |
| 16 | Г.Утыз Имәни. Тәрҗемәи хәле. Иҗатына гомуми күзәтү. Фәнни хезмәтләре.<br>Әдәбият теориясе. Әдәбият тарихы, урта гасыр романтизмы турында белешмә. | 1 | | |
| 17 | Яңа заман татар әдәбияты. XIX гасыр татар әдәбияты. XIX гасырның беренче һәм икенче яртысындагы татар җәмгыятенә характеристика бирү.. Җәмгыять тормышына, мәгърифәтчелек үсешенә тәэсир иткән факторлар. | 1 | | |
| 18 | Класстан тыш уку. Якташ язучылар иҗатына күзәтү. | 1 | | |
| 19 | З.Бигиевнең тормышы, иҗаты. “Мавәрәэннәһердә сәяхәт” әсәре.<br>Әдәбият теориясе. Роман жанры. | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 20 | З.Бигиевнең “Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә” романын уку һәм анализлау. | 1 | | |
| 21-22 | З.Бигиевнең “Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә” романын уку һәм анализлауны дәвам итү. . Әдәбият теориясе. Әдәби процесс, традиция һәм яңачалык. | 2 | | |
| 23 | XIX гасыр башында татар әдәбияты.Гомуми күзәтү. | 1 | | |
| 24-26 | Ф.Әмирханның тормышы һәм иҗаты. “Хәят” повесте. Бай татар зыялыларының гаилә тормышы һәм гореф-гадәтләре. Шул шартларда үскән татар кызының холкы тәрбияләнү, омтылыш-теләкләре чагылу. Рус дөньясы белән аралашып үскән яшь кешенең дөньяга һәм яшәү тәртипләренә карашында каршылыклар туу, моның ул шартларда мәҗбүрият булуы. Дини йолаларны үтәүнең күңелне сафландыруы, шул ук вакытта дини йола-гадәтләрне тарайтып аңлауның шәхес ирегeн киртәләүдәге роле. Язучының кешедәге күңел | 3 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тирбәнешләрен бирүдәге табышлар | | | |
| 27 | Әдәбият теориясе.Рецензия турында белешмә. | 1 | | |
| 28-30 | Г.Камалның тормышы һәм иҗат юлы. Мәгърифәт өлкәсендә күпьяклы эшчәнлеге. Беренче пьесалары. Драматургның сатирик комедияләре. Аларда куелган төп мәсьләләр, тудырылган типлар. Татар җәмгыятенең кимчелекләреннән көлү. “Банкрот” комедиясе. Сюжеты һәм композициясе, образлар системасы. Акчага омтылышның кешене түбәнлеккә, оятсызлыкка төшерү ихтималы. Кешеләрнең бер-берсенә карата ерткычлыгы, хәрәмләшү, алдашуның җирлеге. Комедиянең татар драматургиясе һәм театры өчен әһәмияте, бүгенге көннәргә аваздашлыгы. | 3 | | |
| 31 | Рәфыйка Камалованың ” Әтиемне мин ничек хәтерлим”, Әнәс Камалның “ Әтием портреты”истәлек хикәяләрен уку.<br>**Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятына** | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 32 | **йомгак.**<br>**Б. с. үс.Урта гасыр әдәбияты буенча сочинение.** | 1 | | |
| 33 | 1917-1941 еллар татар әдәбияты. | 1 | | |
| 34 | Мәхмүт Галәүнең тормышы һәм иҗат юлы.<br>” Мөһаҗирләр” әсәре.<br>**Б. с. үс.Урта гасыр әдәбияты буенча сочинение.** | 1<br>1 | | |
| 36 | Бөек Ватан сугышы еллары әдәбияты һәм татар язучылары. | 1 | | |
| 37-39 | Гадел Кутуйның тормыш һәм иҗат юлы.” Сагыну” нәсере.<br>Г.Кутуйның фронттан язган хатлары | 3 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 40-41 | М.Җәлилнең тормышы һәм иҗаты. 20-30 нчы еллар иҗаты | 2 | | |
| 43-44 | М.Җәлилнең сугыш чоры иҗаты.<br>“ Җырларым”,<br>“ Кошчык, “Тик булса иде ирек” , “ Ышанма”шигырьләр енә анализ | 2 | | |
| 45 | Харис Якуповның<br>“ Хөкем алдыннан” картинасы | 1 | | |
| 46-47 | Әмирхан Еники нең тормыш һәм иҗат юлы.<br>Әдәбият теориясе. Реализм агымы. | 2 | | |
| 48-49 | Ә. Еникинең<br>“ Бала”, “ Ана һәм кыз”, “ Кем җырлады?” хикәяләрен укып анализлау. | 2 | | |
| 50 | Сугыштан соңгы һәм 1960-1980 еллар әдәбияты | 1 | | |
| 51-52 | Х.Туфанның тормышы һәм иҗаты. | 2 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 53-54 | Х.Туфан шигырьләрен укып анализлау һәм фикер алышу. | 2 | | |
| 55 | Илдар Юзеевның тормыш һәм иҗат юлы | 1 | | |
| 56 | Илдар Юзеев шигърияте .“Өчәү чыктык ерак юлга” поэмасы. | 1 | | |
| 57 | А.Гыйләҗевның тормышы һәм иҗаты. | 1 | | |
| 58-59 | А.Гыйләҗевның “Җомга көн, кич белән..” повесте. | 2 | | |
| 60 | Нурихан Фәттахның тормыш һәм иҗат юлы. “ Итил суы ака торур” романы. | 1 | | |
| 61-62 | Т.Миңнуллинның тормышы һәм иҗаты. Иҗат үзенчәлекләре. “Кулъяулык” пьесасы | 2 | | |
| 63-64 | Хәзерге татар әдәбияты. Зөлфәт Хәким иҗаты. “ Телсез күке” театраль романы | 2 | | |
| 65-66 | Фоат Садриев иҗаты. “ Таң җиле” романы. | 2 | | |
| 67-68 | Зөлфәт иҗаты | 2 | | |